Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Советының кырык өченче утырышы

Кибәк Иле авыл җирлеге советы утырышы
**КАРАРЫ**

28 март 2019 ел № 121

«Физик затлар милкенә салым турында» Кибәк Иле авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Кибәк Иле авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге «Физик затларның милкенә салым турында» гы 14 номерлы карарына (Советның 2015 елның 15 июнендәге 16 номерлы, 2016 елның 18 ноябрендәге 43 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 93 номерлы, 2018 елның 30 ноябрендәге 110 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пункт өстәргә:

«4. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү:

4.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

4.2. әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар балалары

5. Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатирлар (фатирның бер өлеше, бүлмә) яки торак йортның бер өлеше (торак йортның бер өлеше);

2) гараж яки машина-урыннар.».

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына үзенең теләге белән салым ташламалары бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукынраслаучы документлар бирергә хокуклы.

Салым ташламасы Кибәк Иле авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) салым түләүчеләр тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

Ташламага хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм Россия Федерациясе Салым кодексы белән билгеләнгән срокларда салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра.».

2. 4 һәм 5 пунктлары 6 һәм 7 пунктлары дип санарга.

3. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы И.М.Зиннуров